Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Урман Кәләй авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 16

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге Кәләй тимер юл станциясе поселыгында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 15 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Урман Кәләй авылының Яшел урамында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Яшел урамы, 33 нче йорт.

2. 2019 елның 16 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кәләй тимер юл станциясе. авылының Тимер юл,Гагарин,Үзәк урамнарында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Үзәк урам, 31а йорты, “Шатлык” кибете.

3. 2019 елның 16 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Урман Кәләй авылының Җиңү урамындагы № 1-54, Бакча урамындагы № 1-45, Яшьләр урамындагы № 1-31 йортларында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Җиңү урамы, 28 нче йорт, “Визит” кибете.

4. 2019 елның 17 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Урман Кәләй авылының Гагарин урамындагы күп фатирлы йортларда яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Тимер юл урамы, 38б йорты.

5. 2019 елның 17 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Урман Кәләй. авылының Җиңү урамындагы № 55-125, Бакча урамындагы № 46-111, Яшьләр урамындагы № 31-79, Яр буе, Болын,Ткачик,Бикчурин, Пушкин урамнарында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын Татарстан Республикасы

Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Җиңү урамы, 84 нче йорт.

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Урман Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм элеге ćредстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Кәләй тимер юл станциясе юлларын норматив хәлгә китерү?"

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылында сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

8. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл башкарма комитетын билгеләргә.

9. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Тимер юл урамы, 38б йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

10. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Урман Кәләй
авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев